# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**26 ноябрь 2021 ел** **№ 1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 26 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыен нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында ком-гравий катнашмаларыннан юлларны каплау;

- Азнакай районы Мәсгут авылында зират коймасын алыштыру (монтажлау, панель сатып алу);

- Азнакай районы Мәсгут авылында юлларны кардан чистарту;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында урамнарны яктырту өчен электр җиһазлары сатып алу;;

- Мәсгут авылында үзәкләштерелгән Чишмәдән эчә торган суга анализ;

- Азнакай районы Мәсгут авылында су җыю колонкалары сатып алу;;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 256 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 153.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 153, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныргa:

«Сез, 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында ком-гравий катнашмаларыннан юлларны каплау;

- Азнакай районы Мәсгут авылында зират коймасын алыштыру (монтажлау, панель сатып алу);

- Азнакай районы Мәсгут авылында юлларны кардан чистарту;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында урамнарны яктырту өчен электр җиһазлары сатып алу;;

- Мәсгут авылында үзәкләштерелгән Чишмәдән эчә торган суга анализ;

- Азнакай районы Мәсгут авылында су җыю колонкалары сатып алу;;

- ТР Азнакай районы Мәсгут авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне»).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәсгут авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәсгут авыл җирлеге башлыгы Д.З. Миннеханов